ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

10 август, 2017 ел № 18/4

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең 2018 нче елга һәм 2019, 2020 еллар планы бюджеты проекты буенча гавами тыңлаулар турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль законның 28 маддәсенә, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 19, 28 маддәләренә, Шәһәр Советының 2008 елның 25 сентябрендәге 34/8 санлы Карары белән расланган гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезнамәгә таянып,

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. 2018 елга, 2019 һәм 2020 еллар планы чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты проекты буенча гавами тыңлауларны үткәрү көнен 2017 елның 13 ноябренә, үткәрү вакытын 14:00 сәгатькә тәгаенләргә, гавами тыңлауларны үткәрү урыны итеп Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты бинасында (Х.Туфан проспекты, 23 йорт) 400 залны билгеләргә.
2. 2018 елга, 2019 һәм 2020 еллар планы чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү буенча комиссия составын кушымтадагыча расларга.
3. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ

Шәһәр Советының
18/4 нче Карарына
кушымта
10 август, 2017 ел

2018 елга, 2019 һәм 2020 еллар планы чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү буенча комиссия составы

| | |
|---|---|
| Галиәкбәрова Әлфинур Азат кызы | - комиссия рәисе, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы; |

комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Әхмәтҗанов Ленар Илдар улы | - Башкарма комитетның хокук идарәсе башлыгы; |
| Галиева Ләйсән Ринат кызы | - Башкарма комитетның финанс идарәсе бюджет сәясәте бүлеге башлыгы; |
| Сәгыйдуллина Ирина Алексеевна | - Башкарма комитетның финанс идарәсе башлыгы урынбасары; |
| Хамаева Гөлназ Гарифулла кызы | - Башкарма комитетның финанс идарәсе башлыгы урынбасары, бюджет бүлеге башлыгы. |